| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА<br>ТАТАРСТАН<br>БОЛЬШЕШИНАРСКИЙ<br>СЕЛЬСКИЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>САБИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>422054, Республика Татарстан,<br>Сабинский район,<br>с.Большой Шинар, ул. Кооперативная,<br>36<br>тел. (84362) 41-2-11 | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>422054, Татарстан Республикасы,<br>Саба районы,<br>Олы Шыңар авылы, Кооператив<br>урамы, 36 йорт<br>тел. (84362) 41-2-11 |

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.05.2020

КАРАР
№ 16-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021-2022 нче елларның план чорына салым чыгымнары исемлеген раслау

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гы 06.04.2020 ел 11-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 2 нче пункты нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына салым чыгымнары исемлеген расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемдә калдырам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл башкарма комитетының
28.05.2020 ел 16-п номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның план чорына салым чыгымнары исемлеге**

| Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлдә булу датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең исеме | Салым чыгымнарының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 03 нче апрелендә кабул ителгән 5 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 24 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү | Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балаларны физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү | Өч һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балалар | 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| турында» карары | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 26 нчы ноябрендә кабул ителгән 21 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карары | Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалид ларын җир салымыннан азат итү | Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары | 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2020 елның 1 гыйнварын нан башлап | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |